ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2018 Казан ш. № 10-5/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары нигезендә, «Промочистка» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә салым салу системасы үзгәрүгә бәяле рәвештә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018 елга эчәргә яраклы суга һәм ташландык суны чыгаруга тарифлар билгеләү турында» 2017 елның 1 декабрендәге 10-55/кс номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге карарга кушымтаның 5 пунктының гамәлдә булуы карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «5 | «Промочистка» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | |
| 5.1 | Биккол, Биләркүл, Гәйтән, Егоркино, Ялаур, Заречный, Кычытканлы, Мамык, Би Күле, Урта Камышлы, Төрнәс, Чулпан, Иске Чаллы, Киекле, Иске Әлмәт, Сәләнгеш, Яңа Иглай, Колбай-Мораса, Тимерлек авыл җирлекләре кулланучылары | | | | |
| 5.1.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)** | 24,65 | 25,08 | | |
| 5.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | 20,89 | 21,25 | | » |

5.1.1 пунктчасына текстына түбәндәге эчтәлекле аскы искәрмә өстәргә:

<**> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2016 – 2018 елларга эчәргә яраклы суга, техник суга, ташландык суны чыгаруга, агып төшә торган суларны чистартуга һәм агып төшкән суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 10-31/кс номерлы карарына 1 нче кушымтаның 11 пунктына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 25 мартындагы 10-6/кс номерлы, 2016 елның 9 декабрендәге 10-32/кс номерлы, 2017 елның 30 июнендәге 10-15/кс номерлы, 2017 елның 8 декабрендәге 10-110/кс номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «11 | «Промочистка» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 11.1 | Нурлат шәһәре кулланучылары | | | | | | |
| 11.1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)** | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 32,35 | | 26,11 | | |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 33,50 | | 26,58 | | |
| 11.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | карар үз көченә кергән көннән алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 27,42 | 21,99 | 22,13 | | |
| | | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 28,39 | 22,88 | 22,53 | | » |

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов